ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.02.2020 ел Баулы шәһәре №21

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Балигъ булмаганнарга тәмәке булмаган никотинлы продукция, никотин кертүнең электрон системаларын сатуны тыю һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1нче пунктта «2.15.,» саннарыннан соң «2.16.,» саннарын өстәргә;

«Баулы муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы административ хокук бозулар кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге» карарына кушымтада «ТР КоАПының 2.15 статьясы» юлында «Терроризмны профилактикалау, минимальләштерү һәм (яисә) аның нәтиҗәләрен бетерү буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу» юлларыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| ТР Административ хокук бозулар кодексы 2.16 статьясы.<br>Балигъ булмаганнарга тәмәке булмаган никотинлы | - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге башлыгы һәм баш белгече;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның |

| | |
|---|---|
| продукцияне, никотин кертүнең электрон системаларын сатуны тыюны бозу, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәке булмаган никотинлы продукцияне куллануга җәлеп итү | хокукларын яклау бүлегенең әйдәп баручы белгече; |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И. Гозәеров